| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«САРАБИКУЛОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«САРАБИККОЛ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

**2022 елның 1 июне** **№ 10**

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 24 номерлы карары белән расланган Сарабиккол авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълумат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарына туры китерү һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 апрелендәге 24 номерлы карары белән расланган Сарабиккол авыл җирлегендә хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнарның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Сарабиккол авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешне кертергә:

8 пунктның 3 пунктчасында «,акцияләр» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Сарабиккол авылы Киров урамы 4А,йортта - хакимият бинасында, Киров урамы 3А - гомуми белем бирү мәктәбе бинасында, Пионер урамы 45 йорт - «Сатурн - Урал» ҖЧҖ адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

«Сарабиккол авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге
башлыгы, Совет рәисе Г.Р.Гаделшина

ИНН 1625000704
КПП 164901001